Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Түбән Кондрата авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2020 елның 5 ноябре №2/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Түбән Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 4 февралендәге 2/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Түбән Кондрата авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Түбән Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 4 февралендәге 2/3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;
1.2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Түбән Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәдә (1 нче кушымта):
1 пунктта «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законы белән» сүзләрен «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы белән» сүзләренә алмаштырырга;
8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«8. Конкурста катнашырга теләүчеләр конкурс комиссиясенә гариза бирә, аңа түбәндәге документлар кушып бирелергә тиеш:
1) муниципаль хезмәткә керү һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү турында үтенеч белән гариза;
2) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета;
3) паспорт;

4) хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт кенәгәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;
5) мәгариф турында документ;
6) хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ;
7) Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында физик затны исәпкә кую турында таныклык;
8) запаста булучы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен хәрби исәпкә алу документлары;
9) муниципаль хезмәткә керүгә киртә булырлык авыру булмау турында медицина оешмасы бәяләмәсе;
10) муниципаль хезмәткә керүнең узган елдагы керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;
11) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган белешмәләр;
12) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Түбән Кондрата авыл җирлеге
башлыгы С.В.Васильев